Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 23-ТРЗ

«Татарстан Республикасы
Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының
суд участоклары чикләре турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Алабуга районы һәм Алабуга шәһәре буенча Татарстан Республикасы**
**җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре**
**тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Чапаев һәм Төзүчеләр урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чапаев урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Окружное шоссе урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Окружное шоссе урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба Наратлы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Наратлы урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Пролетарская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны (офис биналарын) кертеп, Пролетарская урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк юнәлештә Нефтьчеләр проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба Нефтьчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнбатышка таба, аннары, уң якта урнашкан йортларны кертеп, Танаев шоссесы урамының күчәр сызыгы буйлап Болгар урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, уң якта урнашкан территорияне («Танайка 2-1», «Наратлык-2» микрорайоннары, «Буа» һәм «Нефтьче» бакчачылык ширкәтләре) кертеп, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт учреждениесе территориясе чиге буйлап төньяк-көнбатыш юнәлештә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнбатыш, алга таба төньяк, аннары көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап (Кама елгасы фарватеры буйлап) төньякка таба Кама елгасының уң ярында, Туймә елгасы тамагында урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, уң якта урнашкан «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт учреждениесе территориясен кертеп, Туймә елгасы үзәне буйлап аның агымына каршы «Ял» бакчачылык ширкәте янында урнашкан Туймә елгасы аркылы җәяүлеләр күперенә кадәр уза, аннары төньякка таба борыла, «Ял» һәм «Салават күпере» бакчачылык ширкәтләренең көньяк, көнчыгыш һәм төньяк чикләре буйлап шәһәр чите буенча уза торган грунтлы юл буйлап уза, алга таба, уң якта урнашкан территорияне (сөрүлек җирләре, бакчалар, көтүлекләр, Шишкин буалары) кертеп, грунтлы юл буенча төньяк-көнчыгышка таба Чаллы шоссесы урамындагы 2 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында, Чаллы шоссесы урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба Чаллы шоссесы урамының күчәр

сызыгы буйлап көнчыгышка таба Чаллы – Казан автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, уң якта урнашкан территорияне кертеп, Чаллы – Казан автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба ягулык салу станциясе янында, Төзүчеләр урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба урман посадкасы чиге буйлап көньяк-көнбатышка таба, Төзүчеләр урамының көнчыгыш ягы буйлап уза, аннары, Төзүчеләр урамын һәм «4-10га» микрорайоны территориясен кертеп, «4-10га» микрорайонының көнчыгыш һәм көньяк читләре буйлап Төзүчеләр урамында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба күпернең көнчыгыш ягы буйлап көньякка таба Төзүчеләр һәм Чапаев урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр уза.

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Алабуга муниципаль районының Бехтерев һәм Поспелово авыл җирлекләре.

## 2 нче суд участогы

2 нче суд участогы чигенә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Яшьләр һәм Пролетарская урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьләр урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Төзүчеләр урамы белән кисешкән ноктага кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Чапаев урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чапаев урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Мәскәү урамы белән кисешкән җиргә (Мәскәү урамындагы 4 нче йорт) кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, шул ук юнәлештә Мәскәү урамының күчәр сызыгы буйлап Городищенская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Городищенская урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба М.Горький урамы белән кисешкән җиргә (М.Горький урамындагы 20 нче йорт) кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, М.Горький урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Гассар урамы белән кисешкән җиргә (Гассар урамындагы 41 нче йорт) кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Гассар урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба М.Горький урамы белән кисешкән җиргә (М.Горький урамындагы 40 нчы йорт) кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, М.Горький урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Чаллы шоссесы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чаллы шоссесы урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Чаллы шоссесы урамындагы 2 нче йортның төньяк-көнчыгыш почмагы янында урнашкан ноктага кадәр уза, аннары көньякка таба борыла һәм, уң якта урнашкан территорияне («Шәһәр яны» микрорайоны, сәнәгать зонасы һәм йортлар) кертеп, шәһәр чите буйлап уза торган грунтлы юл буенча Казан урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, Казан урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Г.Камал урамы белән кисешкән җиргә (Г.Камал урамындагы 16 нчы йорт) кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан

йортларны кертеп, Г.Камал урамының күчәр сызыгы буйлап Нефтьчеләр проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Нефтьчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап Пролетарская урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пролетарская урамының күчәр сызыгы буйлап Яшьләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Алабуга муниципаль районының Илмәт, Олы Качык, Лекарево, Морт, Иске Күклек, Иске Юраш авыл җирлекләре.

**3 нче суд участогы**

3 нче суд участогы чигенә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Пролетарская урамы һәм Танаев шоссесы урамнары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, сул якта урнашкан территорияне (ипподром, «Спутник» гараж ширкәте, «Наратлык» микрорайоны) кертеп, Нефтьчеләр проспектының, аннары Танаев шоссесы урамының күчәр сызыклары буйлап көньяк-көнбатышка таба Болгар урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт учреждениесе территориясен кертеп, «Түбән Кама» милли паркы» федераль дәүләт учреждениесе территориясе чиге буйлап төньяк-көнбатыш юнәлештә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнбатыш чигенә кадәр бара, аннары «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлегенең көнбатыш, алга таба көньяк-көнбатыш чикләре буйлап (Кама елгасы фарватеры буйлап) көньяк юнәлештә Кама елгасының уң ярында, Туймә елгасы тамагында (Туймә елгасы Кама елгасына койган урында) урнашкан ноктага кадәр уза, алга таба, сул якта урнашкан территорияне кертеп, Туймә елгасы үзәне буйлап аның агымына каршы «Ял» бакчачылык ширкәте янында урнашкан Туймә елгасы аркылы җәяүлеләр күперенә кадәр уза, аннары, «Ял» һәм «Салават күпере» бакчачылык ширкәтләре территорияләрен кертеп, грунтлы юл буйлап төньяк юнәлештә Казан урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Казан урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Г.Камал урамы белән кисешкән җиргә (Казан урамындагы 122 нче йорт) кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Г.Камал урамының күчәр сызыгы буйлап Нефтьчеләр проспекты белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Нефтьчеләр проспектының күчәр сызыгы буйлап Пролетарская урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

3 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Алабуга муниципаль районының Костенеево, Мурзиха, Танай авыл җирлекләре һәм Алабуга шәһәренең басу аша кишәрлеге.

**4 нче суд участогы**

4 нче суд участогы чигенә «Алабуга шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлеше керә, аның чиге Яшьләр һәм Пролетарская

урамнарының күчәр сызыклары кисешкән җирдә урнашкан ноктадан алып, так якта урнашкан йортларны кертеп, Яшьләр урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Төзүчеләр урамы белән кисешү ноктасына кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Төзүчеләр урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба Чапаев урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чапаев урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба 13 нче йорт янында Мәскәү урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, шул ук юнәлештә Мәскәү урамының күчәр сызыгы буйлап Городищенская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Городищенская урамының күчәр сызыгы буйлап төньякка таба М.Горький урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, М.Горький урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Гассар урамы белән кисешкән җиргә (Гассар урамындагы 41 нче йорт) кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Гассар урамының күчәр сызыгы буйлап М.Горький урамы белән кисешкән җиргә (М.Горький урамындагы 55 нче йорт) кадәр уза, аннары, так якта урнашкан йортларны кертеп, М.Горький урамының күчәр сызыгы буйлап көнчыгышка таба Чаллы шоссесы урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Чаллы шоссесы урамының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнчыгышка таба Чаллы – Казан автомобиль юлы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, сул якта урнашкан территорияне («Көньяк» микрорайоны, «Уңыш» бакчачылык ширкәте) кертеп, Чаллы – Казан автомобиль юлының күчәр сызыгы буйлап төньяк-көнбатышка таба ягулык салу станциясе янында, Төзүчеләр урамы белән кисешкән җирдә урнашкан ноктага кадәр бара, алга таба Төзүчеләр урамының көнчыгыш ягы буйлап урман посадкасы чиге буенча көньяк-көнбатышка таба, аннары, урман посадкасы территориясен кертеп, «4-10га» микрорайонының көнчыгыш һәм көньяк читләре буйлап Төзүчеләр урамында урнашкан автомобиль күперенә кадәр уза, алга таба күпернең көнчыгыш ягы буйлап көньякка таба Төзүчеләр һәм Чапаев урамнарының күчәр сызыклары кисешкән ноктага кадәр бара, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Чапаев урамының күчәр сызыгы буйлап көнбатышка таба Окружное шоссе урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Окружное шоссе урамының күчәр сызыгы буйлап көньякка таба Наратлы урамы белән кисешкән җиргә кадәр бара, алга таба, так якта урнашкан йортларны кертеп, Наратлы урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк-көнчыгышка таба Пролетарская урамы белән кисешкән җиргә кадәр уза, аннары, җөп якта урнашкан йортларны кертеп, Пролетарская урамының күчәр сызыгы буйлап көньяк юнәлештә Яшьләр урамының күчәр сызыгы белән кисешкән ноктага кадәр уза.

4 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Алабуга муниципаль районының Олы Елово, Олы Шүрнәк, Татар Дөм-Дөме һәм Яковлево авыл җирлекләре.